**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**8 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен**
**татар теленнән үткәрелә торган район олимпиадасы биремнәре**
**(2015/2016 нчы уку елы)**

**Үткәрү вакыты - 3 сәгать** **Максималь балл - 55**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. *Көнбагыш, әнкәй, алдынгы, төнге* сүзләренең язылышы кайсы орфографик принципка туры килә? ***(2 балл)***
   а) фонетик;
   ә) график;
   б) морфологик;
   в) тарихи-традицион.

2. *Кара* сүзенең туры мәгънәдә килгән очрагына туры килгән җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) *Нурлы йөзен аналарның*
   ***Кара** кайгы көйдермәсен*
   ***Кара** ялкын булып* (Р. Җәлиев).
   ә) *Баш өстендә **кара** болытларның куерганнан-куера баруын бик яхшы аңлый иде карт* (Җ. Дәрзаман).
   б) *Тик хәзер инде **кара** белән түгел, карандаш белән генә яза* (Г. Иделле).
   в) *Тик кемнеңдер **кара** әләге белән кулга алдылар үзен, шуннан әйләнеп кайтмады* (Җ. Дәрзаман).

3. Яңгырау авазы саңгыраулашкан сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***

   а) борынгы;
   ә) иҗтимагый;
   б) унбиш;
   в) җыентык.

4. *Материк, континент* сүзләре белән бер синонимик рәткә кергән сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) кыйтга;
   ә) горизонт;
   б) кыйбла;
   в) экватор.

5. Аваз һәм хәреф саны тәңгәл килә торган сүзләр генә кергән җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) Сәгать алтыда килеп, безне үзе белән алып китәргә сүз бирде.
   ә) Иртәгесе өчен китап-дәфтәрләремне әзерләгәч, күңелем тынычланып калды.
   б) Яхшы билгеләр алу өчен, тырышып укырга кирәк.
   в) Дусларым белән Яңа елны каршыларга әзерләнәбез.

6. *Дәфтәрләрен* сүзендәге **–н** кушымчасының төрен билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) сүз ясагыч кушымча;

ә) тартым кушымчасы;
б) килеш кушымчасы;
в) кушымча түгел.

7. ***Бергә*** *эшлибез,* ***бергә*** *ял итәбез* (Ф. Хөсни) җөмләсендәге **бергә** сүзенең кайсы сүз төркеменә керүен билгеләгез. ***(2 балл)***
а) исем;
ә) рәвеш;
б) сан;
в) алмашлык.

8. Ихтималлыкны белдерә торган модаль сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) мөмкин;
ә) түгел;
б) бугай;
в) тәгаен.

9. Бирелгән сүзләрдән шигырь юллары оештырып языгыз. ***(5 балл)***
*Күпкә, белмим, шаулавын,алмамын, урманнары, усак, оныта, уртасында, яфраклары, Тамбов, әллә, ахры, бик, мәңге, озакка, әллә, шаулавын* (Һ. Такташ)

10. *Я, рәхим итегез, Галимулла абзый, үзем пешергән баллы төшне кабып карагыз* (Г. Гобәй) җөмләсенең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***
а) аналитик иярченле кушма җөмлә;
ә) гади җөмлә;
б) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;
в) синтетик иярченле кушма җөмлә.

11. *Бу сәер тойгы күңелдә* ***ниндидер*** *авыр тойгы уятты* җөмләсендәге **ниндидер** сүзе ... ***(2 балл)***
а) тамырдан гына тора;
ә) тамырдан һәм кушымчадан тора;
б) тамыр һәм кисәкчәдән тора;
в) тамыр һәм фигыль ясагыч кушымчадан тора.

12. ***Кондырлы кодача*** фразеологизмының мәгънәсенә туры килгән сүзтезмәне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) ялкау кеше;
ә) көйсез кеше;
б) уйчан кеше;
в) эшчән кеше.

13. Сүзтезмәнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***
*Биш төймәле*
а) исемле сан сүзтезмә;
ә) санлы сыйфат сүзтезмә;
б) сыйфатлы сан сүзтезмә;
в) санлы исем сүзтезмә.

14. Бер составлы җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) Рушад аннан класс журналын сорап алды (М. Мәһдиев).
ә) Бушлыкны ничек тутырырга? (Ә. Баян).

б) Ишекне ачып, коридор буенча чыгып киткәннәрен карап торды (М. Мәһдиев).

в) Ә ипи әҗәте шул көенчә калган ләбаса! (Ә. Гаффар)

15. Тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре куелышының бирелгән җөмләгә туры килә торган аңлатмасын табыгыз. Табышмакның җавабын табыгыз. ***(4 балл)***

*Канаты бар ( ) очалмыйдыр,*
*Күккә таба карамыйдыр,*
*Аяклары юк ( ) йөридер*
*Йолдызларны санамыйдыр,*
*Коры җирдә яшәмидер.*

а) Бүлүче һәм каршы куючы теркәгечләр кабатланып килгәндә, җөмләләр арасына өтер куела.

ә) Җөмлә кисәкләре арасына өтерләр куелган теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә җөмләләр арасына нокталы өтер куела.

б) Теркәгечсез килеп, кискен каршы куюны һәм вакыйгаларның кинәт алмашынуын белдергән җөмләләр арасына сызык куела.


в) Тезү интонациясе, шулай ук каршы куючы теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешкә кергән җөмләләр арасына өтер куела.

16. Җыйнак җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Ислам кинәт торды да дәшми-тынмый китеп барды (М. Хәсәнов).
ә) Болар кызыллар иде, матурлар иде (Г. Ибраһимов).
б) Бүгенге эшне иртәгә калдырмыйлар (Мәкаль).
в) Монда да без бөек Тукайга бурычлы (Г. Бәширов).

## II Теоретик бирем.

Тел белеменең синтаксис тармагында бирелгән схемага туры килгән тел берәмлеге - ... өйрәнелә. Схеманы тутырыгыз. ***(6 балл)***



*“Үлем турында уйлама,*
*Илең турында уйла;*
*Илең турында уйласаң,*
*Гомерең озын бул”, дип язды фронтовик шагыйрь Фатих Кәрим*

Шушы рәвешле язма әсәрләрдән алынган **... сөйләм ...** дип атала. ***(2 балл)***

**III Иҗади бирем.**

*Әйтче, Муса, шундый батырлыкны*
*Кай җиреңдә саклап йөреттең?*
*Кемнән алдың мондый матурлыкны,*
*Нинди ялкыннарда чыныктың?*

Сәйфи Кудаш.

Сәйфи Кудашның шушы сорауларына ничегрәк җавап биреп булыр икән? Фикерләрегезне туплап, 13-14 җөмләдән торган текст итеп языгыз. ***(10 балл)***